СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧЕПЬЯ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
19 декабрь 2025 ел

КАРАР
№ 21

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының 26.04.2021 № 36 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (27.02.2023 № 86, 26.07.2023 № 101, 29.11.2024 № 139 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында**

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 03.10.2025 66-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының 26.04.2021 № 36 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (27.02.2023 № 86, 26.07.2023 № 101, 29.11.2024 № 139 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Нигезләмәнең 11 статьясының 3 пункты түбәндәге редакциядә язылсын:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: югары белем яки урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарында югары, төп һәм әйдәп баручы позицияләр төркемнәре өчен, шулай ук өлкән һәм кече позицияләр төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына: муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - ким дигәндә бер ел яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча ким дигәндә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча ким дигәндә бер ел эшләү.

Әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркем вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиң хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төр вазыйфаларында эшләү стажы да исәпкә алына».

2. Бу карар рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырылсын, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бүлегендә урнаштырылсын.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башлыгына йөкләнсен.

Чепья авыл җирлеге башлыгы А.Г. Нотфуллин